| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАП ТОМБАРЛЫСЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2022г. с. Потапово-Тумбарла № 49

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы Потап-Томбарлы
авыл җирлегендә ачык тыңлаулар,
җәмәгать фикер алышуларын
үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында 2020 ел,
13 март, 124 нче карары

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлегендә ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар үткәрү тәртибе турында 13.03.2020 ел №124 Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пункт. 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, мәгълүмат стендында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә)

тиеш»;

7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ачык тыңлауларда катнашучылар фикер алышуга чыгарылган проект буенча, шул исәптән Баулы муниципаль районы сайты аша да, алдан ук ачык тыңлаулар үткәрү көнендә дә үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен тәкъдим итәргә хокуклы.

Проектны һәм аңа карата мәгълүмати материалларны урнаштыру һәм мондый проект экспозициясен үткәрү чорында гавами тыңлауларда катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының интернеткабул итү сайты аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язмача яки электрон документ формасында;

3) иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән.»;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында «язма рәвештә» сүзләреннән соң «яисә электрон документ формасында» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Потап-Томбарлы авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасында «җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты» абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Кабул ителгән карарларны дәлилләү___________________».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җирлек башлыгы,
Потап-Томбарлы авыл
җирлеге Советы Рәисе Козлова С.А.